РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет «Мальбагушского сельского поселения» Азнакаевского**
муниципального района
ул. Нефтяников дом 30 , с. Мальбагуш
Азнакаевского муниципального района
423308,
тел 37-7-91, факс 37-7-91

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авылы,
Нефтчеләр урамы , 30 йорт
тел 37-7-91, факс 37-7-91

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 январь 2021 ел №1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында.

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыны Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итә:

1. 2021 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6 434,98 (алты мең дүрт йөз утыз дүрт сум, 98 тиен) күләмендә, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http// pravo. tatarstan. ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatarstan. ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А.Й.Әхмәтшин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге башкарма комитет карарына 1 нче кушымта «29» январь 2021 ел № 1

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 148,98 |
| 2. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 963,00 |
| 3. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 313,00 |
| 4. | **Барлыгы** | **6 424,98** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге башкарма комитет карарына 2 нче кушымта «29» январь 2021 ел № 1

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда. |
|---|---|---|
| 1. | Кәфенләү | 841,42 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 307,00 |
| 3. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 963,56 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 313,00 |
| **5.** | **Барлыгы** | **6 424,98** |